Республика Татарстан

Исполнительный комитет
Менделеевского
муниципального района

Татарстан Республикасы

Менделеевск муниципаль
районы
Башкарма комитеты

ПОСТАНОВЛЕНИЕ

КАРАР

22.08.2022 ел

Менделеевск ш.

№501

Мәҗбүри эшләр рәвешендәге
административ җәзалар үтәтү өчен
мәҗбүри эшләр төрләрен һәм
оешмалар исемлеген билгеләү турында

Административ хокук бозулар турында Россия Федерациясе кодексының 3.13 һәм 32.13 статьялары нигезендә Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районы башкарма комитеты мәҗбүри эшләр рәвешендәге административ җәза билгеләнгән затларны төзәтү, аларда нормаларга, җәмгыять кагыйдәләренә, иҗтимагый файдалы хезмәткә карата хөрмәт уяту максатларында, Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районы Башкарма комитеты
КАРАР ИТТЕ:

1. Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районы территориясендә мәҗбүри эшләр рәвешендәге административ җәзалар үтәтүче оешмалар исемлеген һәм Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районы территориясендә административ хокук бозган физик затлар тарафыннан башкарыла торган мәҗбүри эшләр төрләрен кушымта нигезендә билгеләргә.

2. Әлеге карарның кушымтасында күрсәтелгән оешмалар җитәкчеләренә мәҗбүри эшләр рәвешендә җәза үтәү мәсьәләләре буенча суд приставлары хезмәтләре белән хезмәттәшлек өчен җаваплы хезмәткәрләрне билгеләргә;

3. Суд приставлары федераль хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча идарәсенең Менделеевск районы буенча суд приставлары бүлегенә мәҗбүри эшләр рәвешендәге административ җәзалар үтәтүче оешмаларга хокукый һәм методик ярдәм күрсәтергә тәкъдим итәргә.

4. «Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районы территориясендә мәҗбүри эшләр рәвешендәге административ җәзалар үтәтү өчен мәҗбүри эшләр төрләрен һәм оешмалар исемлеген билгеләү турында» Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районы Башкарма комитетының 2021 елның 7 апрелендәге 244 номерлы карарының үз көчләрен югалтуын, «Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районы Башкарма комитетының 2021 елның 7 апрелендәге 244 номерлы карарына үзгәрешләр кертү турында» 2021 елның 11 декабрендәге 754 номерлы карарының үз көчләрен югалтуын танырга.

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат порталында http//pravo.tatarstan.ru бастырып чыгарырга.

5. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең шәһәр хуҗалыгы буенча урынбасарына йөкләргә.

Җитәкче вазыйфасын башкаручы С.В. Метальников

Килештерелде:
Юридик бүлек башлыгы Е.С.Царева

Татарстан Республикасы
Менделеевск муниципаль районы
Башкарма комитетының
2022 елның 22 августындагы
501 номерлы карарына кушымта

Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районы территориясендә административ хокук бозган физик затлар тарафыннан башкарыла торган мәҗбүри эшләр төрләре һәм мәҗбүри эшләр рәвешендә административ җәза үтәтүче оешмалар исемлеге

| Оешманың атамасы | Адресы | Салым түләүченең тәңгәлләштерү номеры (ИНН) | Эшләр төрләре |
|---|---|---|---|
| «Менделеевск муниципаль районының торак-коммуналь хуҗалык идарәсе» муниципаль унитар предприятиесе | 423650, ТР, Менделеевск ш., Фомин ур., 19 й. | 1627009678 | Территорияне җыештыру, очраклы чүп-чар җыю, кар җыю, кар өемнәре, чүп-чарны төяү һәм бушату |
| «Төзекләндерү идарәсе» муниципаль унитар предприятиесе | 423650, ТР, Менделеевск ш., Фомин ур., 19 й. | 1627009540 | Территорияне җыештыру, очраклы чүп-чар җыю, кар җыю, наледи, чүп-чарны төяү һәм бушату, урамнарны себерү |
| Татарстан Республикасы «Менделеевск муниципаль районының административ - хуҗалык учреждениесе» муниципаль бюджет учреждениесе | 423650, ТР, Менделеевск ш., Фомин ур., 19 й. | 1627016851 | Территорияне җыештыру, очраклы чүп-чар җыю, кар җыю, кар өемнәре, чүп-чарны төяү һәм бушату |